# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**(V чакырылыш)**

## КАРАР

**җиденче утырыш**

**3 апрель 2026 ел** **№ 25** **Теләче ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 августындагы № 157 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге территориясендә ваклап сату сәүдә челтәренең эш кагыйдәләренә һәм урам сәүдәсен оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке тарту яисә никотинлы продукция куллану нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 551-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 августындагы № 157 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге территориясендә ваклап сату сәүдә челтәренең эш кагыйдәләренә һәм урам сәүдәсен оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәге урыннарда тәмәке продукциясен яисә никотинлы продукцияне, кальяннарны, никотинлы продукцияне куллану өчен җайланмаларны ваклап сату тыела:»;

2) 1.4 пунктның дүртенче абзацында «шәһәр яны маршрутларына),» сүзләрен «шәһәр яны маршрутларына) һәм аның хәрәкәтенең тукталыш пунктларында (мондый тукталыш пунктында урнаштырылган сәүдә объекты тәмәке продукциясен яисә никотинлы продукцияне, кальяннар, никотинлы продукциясен куллану җайланмаларын сатуның бердәнбер урыны булган очрактан тыш) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: https://tulachi.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге ашлыгы — А.Г. Фатхуллин